**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

**КАРАР**

19.05.2016 Яр Чаллы № 1714

«Район башкарма комитетының архив бүлеге
тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын раслау турында»
Башкарма комитет җитәкчесенең 2014 елның
11 апрелендәге 1478 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Район башкарма комитетының архив бүлегетарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Башкарма комитет җитәкчесенең 2014 елның 11 апрелендәге 1478 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Архив белешмәләрен, архив өземтәләрен, архив документларының күчермәләрен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.14 пункты 1 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.2. Архив документларының урнашу урыны буенча консультация бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.14 пунктын 2 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.3. юридик затларга архивлар эшендә методик һәм практик ярдәм күрсәтү һәм эш башкаруда документлар оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.14 пунктын 3 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.4. муниципаль архивка саклануга ликвидацияләнә торган оешмаларның шәхси составы буенча документлар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.14 пунктын 4 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.5. муниципаль архивның уку залында эшләү өчен кулланучыга архив документларын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.14 пунктын 5 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитетының архив бүлеге башлыгы Н.М. Хаҗрәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев